# ГАДЕЛ КУТУЙ — ЗАМАНДАШЛАРЫ КҮҢЕЛЕНДӘ

Күренекле татар совет язучысы Гадел Кутуй дөньяда озак яшәмәде. Ул 1903 елның ноябрь аенда туа, 1945 елның унбишенче июнендә туган илдән еракта, Польшаның Згеж шәһәрендәге госпитальдә вафат була. Ул чакта аңа нибары кырык ике яшь иде. Шулай булса да, ул үзе белән бергә яшәгән, эшләгән һәм, гомумән, аралашкан кешеләре күңелендә тирән эз калдырган.

Гадел Кутуй турында истәлекләр ул дөньядан киткәч тә языла башлый. 1945 елның җәендә үк Гази Кашшафның язмасы басылып чыга. Илленче елларда да берничә истәлек языла. Әмма истәлекләрнең күбесе җитмешенче елларга туры килә.

Замандашларының хатирәләрендә Гадел Кутуйның кеше буларак сыйфатлары, тормышындагы әһәмиятле вакыйгалар турында языла, аның иҗатының үзенчәлеген, әсәрләрен тирәнрәк аңларга ярдәм итә торган детальләр, эпизодлар искә алына.

Истәлекләрдән күренгәнчә, Кутуйның үз-үзен тотышындагы иң беренче күзгә ташлана, аны башкалардан аерып куя торган сыйфаты — ачык чырайлы булуы, көләчлеге, башкаларга ягымлы мөнәсәбәте. Аның танышлары белән һәм таныш булмаганнар белән дә дустанә мөгамәләсе барлык истәлекләрдә диярлек әйтелә. Ләкин бу әле Гадел Кутуй гел елмаеп кына йөргән, акка да, карага да бер үк мөнәсәбәттә булган икән дигән сүз түгел. Ул кирәк чакта, эш, тормыш, гаделлек таләп иткән чакта кемнең кем булуына карамастан дөреслекне әйткән һәм шактый авырттырып та әйтә белгән. Матбугаттагы принципиаль чыгышлары, мәкалә-фельетоннары, ниһаять, сатирик әсәрләре Гадел Кутуйның тормышка аек күз белән карап яшәүче кеше һәм язучы булганлыгы турында сөйли. Әгәр дә егерменче елларның икенче яртысындагы вакыйгаларга карата гына Кутуйның бу сыйфаты искә алынса, моны гомумән яшьлеккә хас кыюлыктан, алны-артны исәпләп тормаудан гына дип уйларга мөмкин булыр иде. Әмма Гадел Кутуй бик күп бәлаләрне, кимсетү-эзәрлекләүләрне үз башыннан кичергәч тә, зур гаилә башы (аның өч баласы бар), танылган язучы булгач та шундый ук принципиаль, туры сүзле, кыю булып калган. Ширъяздан Сарымсаков, Гомәр Бәширов истәлекләре безгә шул хакта сөйли.

Замандашлары күңелендә Гадел Кутуй бик ягымлы, гадел шәхес буларак сакланган. Ул эшкә, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә карашлар төрлелегеннән килеп чыккан бәхәсләрне, әсәрләрдәге кимчелекләр өчен тәнкыйтьләшүләрне шәхси мөнәсәбәтләргә күчермәгән. Үз әсәрләрен тәнкыйтьләүчеләргә карата күңелендә дошманлык сакламаган кебек, тәнкыйтьле чыгышлары да ниндидер астыртын, яшерен максат, үч алу кебек түбән хисләр белән билгеләнмәгән. Аның телдән әйткән һәм язма тәнкыйтьләренең сәбәбе — әдәбият һәм сәнгатьнең торышы, киләчәге хакында чын күңелдән борчылу. Гадел Кутуй һәрвакыт гадел булып калган.

Язучының истәлекләрдә күрсәтелгән тагын бер сыйфаты шул — ул кешеләр белән бик тиз танышып, аралашып китә торган булган. Эчкерсезлеге өчен аны яратканнар, хөрмәт иткәннәр. Ул үзе эшләгән коллективларда укытучылар, журналистлар һәм язучылар белән, соңгы гомерендә солдатлар һәм командирлар белән аралашкан, һәр җирдә ягымлы иптәш, турылыклы дус буларак ихтирам казанган, үзенә тапшырылган эшне яхшы итеп башкара алган, файдалы һәм намуслы хезмәткәр булган.

Күпләр аны үзенең дусты санаган. Гази Кашшаф, Риза Ишморат, Фатыйма Ильская, Ширъяздан Сарымсаковлар Кутуйны җан дуслары итеп язалар. Якын дусларының бик күбесе Гадел Кутуй турында истәлекләрен калдыра алмадылар: Һади Такташ, Камал III, Фаикъ Әсгать, Әсгать Мәҗит һ. б.

Гадел Кутуйның бик самими, ихлас күңелле, тиз аралашучан булуы, бәлки, бала һәм үсмер чагындагы тормыш шартларыннан киләдер. Язучының әтисе Нурмөхәммәт ага һәм аның ике өлкән улы үзләренең хатын, бала-чагалары белән зур бер гаилә булып бергә яшәгәннәр. Куйбышевтан җиде чакырымдагы Кряж дигән поселокның Казанская урамында аларның ике катлы таш йортлары булган. Шунда бергә торганнар, һөнәрчелек мастерскойларында олысы-кечесе бергәләп эшләгәннәр. Кутуевларның ишле семьясында олыны олы, кечене кече итү, башкаларга игътибарлы булу, олылар һәм кечеләр белән мөгамәләдә уртак тел таба белү сыйфатлары тәрбияләнгән.

Язучы һәм журналист өчен гаять кирәкле бу сыйфатлар Бөек Ватан сугышы елларында, канлы сугыш эчендә солдатлар белән аралашуда да, дивизион парторгы буларак политик аңлату эшләре алып барганда да Гадел Кутуйга бик нык ярдәм иткән. Үзенең рухи пакьлегенә, белеменә, фикеренә нык таяна алган зур эчке культуралы кеше генә үзен шулай гади, самими, ихлас тота ала. Гадел Кутуйга исә ул сыйфатлар хас.

Истәлекләрдә аның чамадан тыш хезмәт сөючәнлеге дә әйтелә. Ул бик күп укыган. Көнбатыш, рус, Көнчыгыш әдәбиятын, тарихны, әдәбият теориясен бик яхшы белгән. Хатип Госман

сүзләре белән әйткәндә, «эрудиция дигәндә ул чын мәгънәсендә галим, ул үзе бер университет».

Тагын шунысын да әйтергә кирәк: Гадел Кутуйның бик белемле булуы башкалар язганны укудан гына туган белем түгел. Ул үзе күп нәрсәләр турында уйланган, уй-фикерләрен рецензияләрендә, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә багышланган тирән эчтәлекле мәкаләләрендә, чыгышларында практика белән, тормыш белән бәйли белгән.

Кутуй — искиткеч оста оратор. Аны тыңлаган кеше ул сөйләгәннәргә карата битараф кала алмаган. Яхшы сөйләве, күп нәрсәдән хәбәрдарлыгы һәм белеме аркасында ул укытучы, педагог буларак за зур уңышларга ирешкән.

Менә шундый төскә чибәр, сүзгә оста, нәрсәгә тотынса, шул кулыннан килә торган акыллы һәм эшчән Кутуйның тормыш юлы чәчәкләр белән генә бизәлмәгән. Үзе ачык чырайлы, көләч бер кеше булса да, тормыш аңа гел ачык чыраен гына күрсәтмәгән. Язучының иҗатын дөрес аңлау өчен аларны да белергә кирәк. Истәлек авторлары бу хакыйкатьне дә онытмыйлар.

Кутуй кичергән иң зур фаҗига — җидегәнчелек мәсьәләсе. Түбән, вак җанлы кешеләрнең көнчелегеннән килеп чыккан ул яла безнең татар совет әдәбиятына зур зыян китерде. Кутуйның Гази Кашшафка фронттан язган бер хатында мондый юллар бар: «Син үткәргән кичә хәтердә озак сакланачак. Андый зур мәҗлеснең төп кунагы булу түгел, аннан күп түбән җыелышлардан куып чыгарылганым бар».

Шундый шартларда гаделлеккә ышанычыңны саклап калу, сынмас, сыгылмас өчен кешедә гаять зур рухи көч булырга тиеш. Һәм андый көч Кутуйда булган. Җидегәнчелек шаукымы байтакка сузылса да, Кутуй яшәү, иҗат итү дәртен югалтмаган. 1937 елда Х. Рәхим дигән берәү «Кызыл Татарстан» газетасында (9 август санында), «Җидегәнче Кутуйның «Шатлык җыры» турында» исемле рецензия белән чыккан. Бу инде исәнләшми китеп, күрмәмешкә салышып кешене кимсетү генә түгел, бу — документ. Һәм Гадел Кутуй авторны судка бирә. Суд исә әлеге рецензияне яла ягу дип бәяли.

Совет судының рәсми рәвештә Кутуйның гаепсез икәнлеген тануы, «Тапшырылмаган хатлар» повестена Муса Җәлил биргән югары бәя, повестьның татар һәм рус укучылары тарафыннан бик яхшы кабул ителүе язучыга моннан соң тыныч күңел белән иҗат итәргә шартлар тудыра.

Гадел Кутуйның шатлыклы һәм борчулы вакыйгаларга бай гомер юлы җыентыкка кергән истәлекләрдә шактый тулы ачыла. Аның шәхси тормышы, язучылар белән мөнәсәбәтләре һәм әдәби хәрәкәткә катнашуы, артистлар һәм сәхнә тормышындагы роле,

театр сәнгатенә мәхәббәте хакында каләмдәшләре, дуслары, фикердәшләре, туганнары яза.

Гадел Кутуй оештыру эшенә бик сәләтле булган. Ул вакыйгаларның эченә бик тиз үтеп керә, кайда, нәрсә, ничек эшләргә мөмкин икәнен бик тиз чамалый һәм шунда ук тиешле чараларны да күрә башлый. Г. Минский, Р. Ишморат, Ф. Ильская Казанга Максим Горький һәм Владимир Маяковский килгән көннәрне, шул вакытта Гадел Кутуйның матбугат өчен материаллар яздыруы, төрле очрашулар оештырып йөрүе, аның бу эштәге тапкырлыгы һәм житезлеге турында язалар.

Язучы тормышының истәлекләрдә ачылып житмәгән ягы — аның Казан төзүче инженерлар институтында һәм авиация техникумындагы эшчәнлеге. Аның иҗат чишмәсен институтта һәм техникумда укыту, эшләү тәҗрибәсе дә баеткан бит. Әсәрләренә материалны ул аннан да алган. Мәсәлән, «Солтанның бер көне» хикәясенен төп герое Солтан — укытучы, икенчесе — Роза — төзүче инженерлар институтын тәмамлаучы студент кыз. «Шатлык җыры» пьесасында, «Нишләргә» һәм «Вөждан газабы» хикәяләрендә галимнәр, укытучылар, студентлар тормышы тасвирлана.

Бөек Ватан сугышы чоры истәлекләрдә шулай ук шактый тулы чагылыш тапкан. Ул утлы еллар — Гадел Кутуй өчен гаять әһәмиятле заман. Сугыш вакытында язучының ватанчылык сыйфатлары, кыю, батыр табигате тагын да тулырак ачыла. Илебез өчен иң дәһшәтле көннәрдә Сталинград янында Коммунистлар партиясе сафына кереп, язучы күптәнге теләгенә ирешә, ораторлык сәләте аңа сугышчылар арасында политик агарту эшен бик яхшы алып барырга мөмкинлек бирә.

Истәлекләрне җыентыкка урнаштыру тәртибе Гадел Кутуйның тормыш хронологиясеннән чыгып билгеләнде. Истәлекләр арасында язучы тормышының аерым чорларына караганнары булган кебек, аның бөтен гомерен иңләгәннәре дә бар. Мәсәлән, Галимә Кутуева, Риза Ишморат, Гази Кашшаф истәлекләре. Җыентыкны Гадел Кутуйның апасы Зәйнүл Кутуева истәлеге белән башлап җибәрү күлай табылды. Чөнки Зәйнүл Мөхәммәтовна язучының бала һәм үсмер чагы, уку еллары, гаиләләрендәге гореф-гадәтләр белән таныштыра. Аннары Галимә Кутуева, Риза Ишморат истәлекләре китә — алар Гадел Кутуй тормышындагы аерым вакыйгаларга бәйләнешле истәлекләрне тулырак, кинрәк аңларга ярдәм итәләр.

Гази Кашшаф истәлеге җыентыкны тәмамлау рәвешендә азакка урнаштырылды. Ул Гадел Кутуйның гомер юлын замандашы һәм дусты булып кына түгел, галим, әдәбият белгече буларак та яктырта, Гадел Кутуйны шәхес һәм язучы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе итеп күз алдына бастыра.

*Розалия Нуруллина*